| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ<br>ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

18 июнь 2026 ел № 6127

Башкарма комитетның «2025-2027 елларга Яр Чаллы шәһәрендә дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыру» муниципаль программасын раслау турында» 2024 елның 22 октябрендәге 6968 номерлы Карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Президентының 2025 елның 25 ноябрендәге 858 номерлы Указы белән расланган 2036 елга кадәр чорга Россия Федерациясенең дәүләт милли сәясәте стратегиясе, шәһәр Уставы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты, Башкарма комитетның «Муниципаль программаларны эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2017 елның 11 сентябрендәге 5326 номерлы Карары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «2025-2027 елларга Яр Чаллы шәһәрендә дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыру» муниципаль программасын раслау турында» 2024 елның 22 октябрендәге 6968 номерлы Карарына (Башкарма комитетның 2026 елның 30 апрелендәге 4153 номерлы Карары редакциясендә), кушымтаны кушымтада каралганча яңа редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://nabchelny.ru адресы буенча Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары В.Х. Харисовка, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

УПРАВЛЕНИЕ ДЕЛОПРОИЗВОДСТВОМ
ЭШ КӘГАЗЬЛӘРЕН АЛЫП БАРУ ИДАРӘСЕ

Башкарма комитетның
2026 елның 18 июнендәге
6127 номерлы карарына
кушымта

Башкарма комитетның
2024 елның 22 октябрендәге
6968 номерлы карарына
кушымта

«2025-2027 елларга Яр Чаллы шәһәрендә дәүләт
милли сәясәтен тормышка ашыру»
муниципаль программасы

1 бүлек. «2025-2027 елларга Яр Чаллы шәһәрендә дәүләт
милли сәясәтен тормышка ашыру»
муниципаль программасының паспорты

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | «2025-2027 елларга Яр Чаллы шәһәрендә дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыру программасы» (алга таба – программа) |
| Программаны эшләү өчен нигез (хокукый актның исеме, номеры һәм датасы) | Россия Федерациясе Президентының 2025 елның 25 ноябрендәге 858 номерлы Указы белән расланган 2036 елга кадәрге чорга Россия Федерациясенең дәүләт милли сәясәте стратегиясе;<br>Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 15 апрелендәге 317 номерлы карары белән расланган «Мәдәниятне үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасы.<br>Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында Дәүләт милли сәясәте концепциясен раслау турында» 2008 елның 3 июлендәге ПУ-312 номерлы Указы.<br>Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 18 декабрендәге 1006 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыру» дәүләт программасы |
| Программаны төп эшләүчеләр | Башкарма комитетның мәдәният идарәсе (алга таба – мәдәният идарәсе). |
| Программаны үтәүчеләр | Мәдәният идарәсе, Башкарма комитетның мәгариф идарәсе, Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе, Башкарма комитетның мәгълүмати сәясәт һәм җәмәгатьчелек белән элемтә идарәсе. |

<table>
<tr><td>Программаның максаты</td><td colspan="5">Шәһәрнең күпмилләтле халкының бердәмлеген саклау, шәһәрдә тотрыклы үсешне, социаль һәм икътисадый тотрыклылыкны тәэмин итү өчен этномәдәни һәм тел күптөрлелеген саклап, гомумроссия гражданлык тәңгәллеген (гражданнар үзаңын) ныгыту</td></tr>
<tr><td>Программаның бурычлары</td><td colspan="5">1. Җирле үзидарә органнарының, милли-мәдәни һәм дини берләшмәләрне дә кертеп, граждан җәмгыяте институтлары белән үзара хезмәттәшлеген камилләштерү аша милләтара һәм конфессияара тынычлыкны һәм татулыкны тәэмин итү, милли (этник) һәм (яки) дини конфликтларны кисәтү.<br>2. Россиянең традицион рухи-әхлакый һәм мәдәни-тарихи кыйммәтләре нигезендә, шул исәптән балаларны һәм яшьләрне патриотик тәрбияләү, тарихи туган якны өйрәнүне үстерү һәм Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы дәүләт символларына ихтирамлы мөнәсәбәт формалаштыру юлы белән гражданнар бердәмлеген һәм гомумроссия гражданлык тәңгәллеген (гражданнар үзаңын) ныгыту.<br>3. Яр Чаллы шәһәренең этномәдәни һәм тел күптөрлелеген саклау һәм аңа ярдәм итү, татар һәм рус телләренең (милләтра аралашу теле буларак рус телен дә кертеп) яшәве өчен шартлар тудыру, барлык халыкларның туган телләрен һәм мәдәниятләрен үстерү, шулай ук рус теле, Россия Федерациясенең хокукый нигезләре, Татарстан халыкларының традицияләре һәм мәдәнияте белән танышу аша мигрантларның социомәдәни адаптациясенә һәм Россия җәмгыятенә интеграциясенә ярдәм итү.<br>4. Дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыруны мәгълүмати тәэмин итү, толерантлык, гражданнар бердәмлеге идеяләрен пропагандалау, башка мәдәниятләргә хөрмәт күрсәтү өчен бердәм мәгълүмати киңлек формалаштыру</td></tr>
<tr><td>Программаны тормышка ашыру сроклары һәм этаплары</td><td colspan="5">2025-2027 еллар</td></tr>
<tr><td rowspan="4">Еллар буенча бүлеп, программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары</td><td rowspan="2">Финанслау чыганаклары</td><td colspan="4">Программаны тормышка ашыру еллары</td></tr>
<tr><td>2025 ел</td><td>2026 ел</td><td>2027 ел</td><td>Тормышка ашыру чорында барлыгы (мең сум)</td></tr>
<tr><td>Муниципаль бюджет</td><td>2 066,8</td><td>2 066,8</td><td>2 066,8</td><td>6 200,4</td></tr>
<tr><td>Федераль бюджет</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td></tr>
</table>

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | Республика бюджеты | - | - | - | - |
| | Башка чыганаклар | - | - | - | - |
| | Барлыгы | 2 066,8 | 2 066,8 | 2 066,8 | 6 200,4 |
| | Искәрмә: финанслау күләмнәре прогноз характерга ия һәм Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты мөмкинлекләрен исәпкә алып, аларга ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш. | | | | |
| Программаны тормышка ашыруның көтелгән нәтиҗәләре һәм нәтиҗәлелек күрсәткечләре | Программаны тормышка ашыруның йомгаклау нәтиҗәләре:<br>- гражданнар бердәмлеген, шәһәрдә яшәүчеләрнең гомумроссия гражданлык тәңгәллеген ныгыту, муниципаль берәмлек территориясендә бердәм мәдәни киңлек формалаштыру;<br>- дәүләт телләре буларак рус һәм татар телләрен, шулай ук шәһәрдә яшәүче барлык халыкларның туган телләрен саклау, үстерү һәм аларга ярдәм итү, телләр күптөрлелеген тәэмин итү;<br>- татар халкының мәдәниятен саклау һәм үстерүне дә кертеп, Яр Чаллыда яшәүче барлык халыклар вәкилләренең этномәдәни ихтыяҗларын канәгатьләндерү;<br>- шәһәр территориясендә милләтара (этникара) һәм динара мөнәсәбәтләр өлкәсендә конфликтлы хәлләрне булдырмау һәм тыныч юл белән хәл итү;<br>- чит ил гражданнарының социаль һәм мәдәни адаптациясе өчен шартлар тудыру, аларны Россия җәмгыятенә интеграцияләү, милли һәм дини нигездә анклавлар формалаштыруга юл куймау, шулай ук дәүләт милли сәясәте кысаларында регионара һәм халыкара хезмәттәшлекне үстерү | | | | |
| Программаны тормышка ашыруга контроль оештыру системасы | Программа үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет гамәлгә ашыра. | | | | |

## 2 бүлек. Проблеманың эчтәлеге һәм аны программа алымы белән хәл итү кирәклеген нигезләү

Программа Россия Федерациясе Президентының «2036 елга кадәрге чорга Россия Федерациясенең дәүләт милли сәясәте стратегиясе турында» 2025 елның 25 ноябрендәге 858 номерлы һәм Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында Дәүләт милли сәясәте концепциясен раслау турында» 2008 елның 3 июлендәге ПУ-312 номерлы Указлары нигезендә эшләнде.

Күрсәтелгән стратегик документларда беркетелгән принципларга һәм өстенлекләргә таянып, әлеге программа Яр Чаллы шәһәрендә дәүләт милли сәясәтен

тормышка ашыруның, шәһәр территориясендә яшәүче барлык халыкларның этномәдәни ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен оптималь шартлар тудыруга, милләтара һәм конфессияара тынычлыкны һәм татулыкны саклауга, шулай ук мигрантларның уңышлы социомәдәни адаптациясе һәм интеграциясенә юнәлдерелгән максатларын, бурычларын һәм механизмнарын билгели.

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә милләтара мөнәсәбәтләрнең торышы тотрыклылык, төрле этник төркемнәр һәм конфессияләр вәкилләренең үзара тату эшчәнлеге һәм хезмәттәшлеге белән характерлана. Үзара хөрмәткә һәм ышанычка нигезләнгән милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр муниципаль хакимият органнарының аерым кайгырту предметы булып тора, алар үз эшчәнлекләрен иҗтимагый этномәдәни берләшмәләр, дини оешмалар һәм граждан җәмгыятенең башка институтлары белән үзара хезмәттәшлектә гамәлгә ашыралар.

Яр Чаллы шәһәре - Татарстан Республикасының күпмилләтле һәм поликонфессияле муниципаль берәмлеге. Аның үсеше хәзерге заман Татарстан территориясендә яшәүче халыкларның тыгыз этномәдәни үзара йогынтысы һәм традицияләрнең үзара бәйләнеше белән характерлана. Бу процесста традицион рәвештә әйдәп баручы ролен шәһәр халкының күпчелеген тәшкил иткән татар һәм рус халыклары вәкилләре уйный. Бу халыкларның мәдәниятен, телен һәм гореф-гадәтләрен үзара баету җирле җәмгыять үсешенең характерлы бер үзенчәлегенә әверелде.

Төрле мәдәният һәм дин вәкилләренең күп еллар бергә яшәү чорында Яр Чаллыда барлыкка килгән дус-туганлык традицияләре хәзерге вакытта да саклана. Моңа гомумроссия гражданлык тәңгәллеген формалаштыру, яшь буынны Татарстан Республикасында яшәүче халыклар мәдәниятенә, теленә, традицияләренә һәм гореф-гадәтләренә хөрмәт белән карау рухында тәрбияләү, шулай ук гуманитар белем бирү ролен күтәрү буенча максатчан эшләү ярдәм итә.

Шәһәрнең милли җәмгыятьләре каршында милли мәдәниятне, телләрне һәм традицияләрне сөючеләрнең 13: «Путене» чуаш, «Гөрләвек» башкорт, «Киликиа» әрмән, «Хары-Бюльбюль» азәрбайҗан, «Эрвий» мари, «Лезгияр» лезгин, «Inspiration» Россия немецлары, «Игәнәй» керәшен, «Җанагай» керәшен, «Наири» әрмән, «Зангак» әрмән, «Кизилиос» удмурт, «Вахдат» таҗик клубы эшли. Клубларда талантлы җитәкчеләр — милли җәмгыятьләр вәкилләре эшли. Һәр клубта уртача 15 әр кеше шөгыльләнә, төрле яшьтәге 165 тән артык кеше зур канәгатьлек белән милли клублар дәресләренә йөри.

Идарә системасы, мәгариф, мәдәният, яшьләр сәясәте һәм массакүләм мәгълүмат чаралары учреждениеләре кадрларының этномәдәни үсеш, милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр, шулай ук мигрантларны хокукый агарту һәм аларның социомәдәни адаптациясе һәм җәмгыятькә интеграциясе мәсьәләләрендә квалификацияләрен һәм компетентлыгын күтәрү мөһим бурыч булып тора.

Конфессияара татулык һәм бердәмлекне, мигрантларның социомәдәни адаптациясен һәм интеграциясен тәэмин итүдә гражданлык җәмгыяте институтлары зур роль уйный. Алар арасында Татарстан халыклары Ассамблеясының Яр Чаллы филиалы, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карамагындагы дини һәм иҗтимагый оешмалар белән үзара эшчәнлек Советы мөһим урын тота.

Шәһәрдә 39 дини оешма теркәлгән, шул исәптән: 18 - мөселман, 12 - православие, 1 - иске дин җәмгыяте, 7 - протестант, 1 яһүд оешмасы бар. Традицион дини агым вәкилләре милләтара һәм конфессияара ызгышларны булдырмауга юнәлдерелгән агарту эшләре алып баралар, шәһәр һәм район чараларында актив катнашалар. Традицион дини берләшмәләр даими рәвештә Башкарма комитет белән үзара эшчәнлек алып баралар.

Җирле үзидарә органнарының системалы эше, Яр Чаллы шәһәре территориясендә милли һәм дини берләшмәләр лидерлары белән үзара эшчәнлек нәтиҗәсендә 2024-2025 елларда милләтара һәм динара конфликтлар теркәлмәгән.

Шул ук вакытта программа-максатчан методлар белән комплекслы якын килүне һәм хәл итүне таләп итә торган тышкы һәм эчке мәсьәләләр дә саклана. Аларга түбәндәгеләр керә:

- тышкы деструктив мәгълүмати йогынты шартларында этникара интеграцияне һәм бердәмлекне ныгыту бурычларының масштаблылыгы һәм күпкырлылыгы;

- тарихны фальсификацияләү омтылышларына, ксенофобия, русофобия һәм неонацизм идеологиясен таратуга каршы тору зарурлыгы;

- халыкларның телләрен, мәдәниятләрен һәм традицияләрен саклау һәм үстерү мәсьәләләрен дә кертеп, милләтара мөнәсәбәтләрне җайга салу процессының күп аспектлылыгы;

- гомумгражданлык килешүен формалаштыруның социаль, этник, миграцион һәм икътисадый аспектларының үзара бәйләнеше;

- чит ил гражданнарын социомәдәни адаптацияләү һәм интеграцияләү, милли һәм дини нигездә анклавлар формалаштыруга юл куймау буенча эшне көчәйтү зарурлыгы;

- дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыруда һәм экстремизмны профилактикалауда җирле үзидарә органнарының, милли-мәдәни берләшмәләрнең һәм дини оешмаларның үзара эшчәнлеген алга таба камилләштерү мөһимлеге.

Программа Яр Чаллы шәһәрендә милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрнең позитив характерын саклауга һәм ныгытуга, үзара хөрмәт һәм дус-туганлык традицияләре нигезендә гражданнарның этномәдәни ихтыяҗларын канәгатьләндерүгә ярдәм күрсәтүгә юнәлдерелгән. Программа чараларын тормышка ашыру этникара мөнәсәбәтләр өлкәсендә мөмкин булган проблемаларны булдырмый калырга, шәһәрнең күпмилләтле халкының этномәдәни үсешен сакларга һәм яхшыртырга, 2036 елга кадәр чорга Россия Федерациясе дәүләт милли сәясәте стратегиясендә һәм Татарстан Республикасы дәүләт милли сәясәте концепциясендә каралган максатчан күрсәткечләргә ирешүне тәэмин итәргә мөмкинлек бирәчәк.

## 3 бүлек. Программаның тормышка ашыру сроклары һәм этаплары күрсәтелгән төп максатлары, бурычлары

Программаның максаты - шәһәрнең күпмилләтле халкының бердәмлеген саклау, шәһәрдә тотрыклы үсешне, социаль һәм икътисадый тотрыклылыкны тәэмин итү өчен этномәдәни һәм тел күптөрлелеген саклап, гомумроссия гражданлык тәңгәллеген (гражданнар үзаңын) ныгыту.

Программаның бурычлары булып тора:

1) Россиянең традицион рухи-әхлакый һәм мәдәни-тарихи кыйммәтләре нигезендә, шул исәптән балаларны һәм яшьләрне патриотик тәрбияләү, тарихи туган якны өйрәнүне үстерү һәм Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы дәүләт символларына ихтирамлы мөнәсәбәт формалаштыру юлы белән гражданнар бердәмлеген һәм гомумроссия гражданлык тәңгәллеген (гражданнар үзаңын) ныгыту;

2) җирле үзидарә органнарының, милли-мәдәни һәм дини берләшмәләрне дә кертеп, граждан җәмгыяте институтлары белән үзара хезмәттәшлеген камилләштерү аша милләтара һәм конфессияара тынычлыкны һәм татулыкны тәэмин итү, экстремизмны профилактикалау, милли (этник) һәм (яки) дини конфликтларны кисәтү;

3) Яр Чаллы шәһәренең этномәдәни һәм тел күптөрлелеген саклау һәм аңа ярдәм итү, татар һәм рус телләренең (милләтара аралашу теле буларак рус телен дә кертеп) яшәве өчен шартлар тудыру, барлык халыкларның туган телләрен һәм мәдәниятләрен үстерү, шулай ук рус теле, Россия Федерациясенең хокукый нигезләре, Татарстан халыкларының традицияләре һәм мәдәнияте белән танышу аша мигрантларның социомәдәни адаптациясенә һәм Россия җәмгыятенә интеграциясенә ярдәм итү;

4) дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыруны мәгълүмати тәэмин итү, толерантлык, гражданнар бердәмлеге идеяләрен пропагандалау, башка мәдәниятләргә хөрмәт күрсәтү өчен бердәм мәгълүмати киңлек формалаштыру, шулай ук ксенофобия, экстремизм таралуга һәм тарихны фальсификацияләүгә каршы тору.

Күрсәтелгән максатларга һәм бурычларга ирешү программага кергән чаралар кысаларында гамәлгә ашырылачак.

## 4 бүлек. Программаны ресурслар белән тәэмин итү

| Чыгымнарның чыганаклары һәм юнәлешләре | Финанслауның күләме (мең сум) | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Барлыгы | Шул исәптән еллар буенча | | |
| | | 2025 ел | 2026 ел | 2027 ел |
| Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 6 200,4 | 2 066,8 | 2 066,8 | 2 066,8 |
| Барлыгы | 6 200,4 | 2 066,8 | 2 066,8 | 2 066,8 |

## 5 бүлек. Нәтиҗәлелекне бәяләү һәм көтелгән нәтиҗәләр

Программаны тормышка ашыруның нәтиҗәлелеге, «Яр Чаллы шәһәрендә дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыру» муниципаль программасы нигезендә эшләнгән хокукый, оештыру, социаль-икътисадый, мәгълүмати һәм башка чаралар комплексын гамәлгә ашырып, җирле үзидарә органнарының, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнарының һәм граждан җәмгыяте институтларының килештерелгән эшчәнлеге белән тәэмин ителә.

Программаны тормышка ашыру түбәндәгеләрне тәэмин итәргә мөмкинлек бирәчәк:

- татар һәм рус телләрен саклауны һәм үстерүне дә кертеп, шәһәр халыкларының этномәдәни үсеше өчен шартларны яхшырту;
- гомумроссия гражданлык тәңгәллеге дәрәҗәсен арттыру һәм гражданлык бердәмлеген ныгыту;
- мигрантларның социомәдәни адаптациясе һәм интеграциясе системасын саклау;
- милли һәм дини нигездә конфликтлар куркынычын киметү, яшьләр арасында толерант мохит формалаштыру;
- толерантлык һәм гражданнар бердәмлеге идеяләрен пропагандалау өчен бердәм мәгълүмати киңлек формалаштыру;
- яшьләр арасында үз шәһәренең һәм Татарстан Республикасының мәдәниятен һәм тарихын өйрәнүгә кызыксынуны үстерү.

| № т/б | Индикаторның исеме | Исәпләү формуласы |
|---|---|---|
| 1. | Яр Чаллы шәһәрендә милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрне гармонияле итүгә юнәлдерелгән чараларда катнашучыларның өлеше | $$\frac{N}{D} * 100\%$$ N – Яр Чаллы шәһәрендә милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрне гармонияле итүгә юнәлдерелгән чараларда катнашучыларның саны;<br>D – Яр Чаллы шәһәрендә милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрне гармонияле итүгә юнәлдерелгән чараларда катнашучыларның гомуми саны. |
| 2. | Яр Чаллы шәһәрендә яшәүче халыкларның этномәдәни (бу – гражданнарның этник, этномәдәни яки дини принциплар буенча традицион эшләүче яки күптән түгел үзеннән-үзе оешкан берләшмәләр) үсешенә юнәлдерелгән чараларда катнашучылар саны | Яр Чаллы шәһәрендә яшәүче халыкларның этномәдәни үсешенә юнәлдерелгән чараларда катнашучыларның санын ел саен арттыру планлаштырылган. |

6 бүлек. Нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, программа чаралары һәм чаралар буенча финанслау

| Чараларның исеме | Башкару чылар | Тормышка ашыру сроклары | Максатчан индикаторлар һәм нәтиҗәлелек күрсәткечләре, үлчәү берәмлекләре | Индикаторларның зурлыгы | | | | Финанс лау чыганак лары | Чыганакны күрсәтеп, финанслау күләме, мең сум | | | Көтелгән нәтиҗә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2024 ел (бәя ләү) | 2025 ел | 2026 ел | 2027 ел | | 2025 ел | 2026 ел | 2027 ел | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 |
| Максатларның исеме: шәһәрнең күпмилләтле халкының бердәмлеген саклау, шәһәрдә тотрыклы үсешне, социаль һәм икътисадый тотрыклылыкны тәэмин итү өчен этномәдәни һәм тел күптөрлелеген саклап, гомумроссия гражданлык тәңгәллеген (гражданнар үзаңын) ныгыту | | | | | | | | | | | | |
| | | 2025-2027 еллар | Яр Чаллы шәһәрендә милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрне гармонияле итүгә юнәлдерелгән чараларда катнашучылар өлеше, % | 68,4 | 69,6 | 70 | 70,4 | | | | | |
| | | 2025-2027 еллар | Яр Чаллы шәһәрендә яшәүче халыкларның этномәдәни үсешенә юнәлдерелгән чараларда катнашучылар саны, кеше | 55 120 | 56 525 | 57 715 | 58 120 | | | | | |

| | Чараларның исеме | Башкаручы лар | Тормышка ашыру срок лары | Максатчан индикаторлар һәм нәтиҗәлелек күрсәткеч ләре, үлчәү берәмлекләре | Индикаторларның зурлыгы | | | | Финанслау чыганак лары | Чыганакны күрсәтеп, финанслау күләме, мең сум | | | Көтелгән нәтиҗә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | 2024 ел (бәяләү) | 2025 ел | 2026 ел | 2027 ел | | 2025 ел | 2026 ел | 2027 ел | |
| | 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 |
| Бурычның исеме: 1. җирле үзидарә органнарының, милли-мәдәни һәм дини берләшмәләрне дә кертеп, граждан җәмгыяте институтлары белән үзара хезмәттәшлеген камилләштерү аша милләтара һәм конфессияара тынычлыкны һәм татулыкны тәэмин итү, милли (этник) һәм (яки) дини конфликтларны кисәтү | | | | | | | | | | | | | |
| 1. | Чараларны оештыручылар ягыннан «Җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар уздыру турында» 2004 елның 19 июнендәге 54-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә гавами чаралар оештыру һәм үткәрү тәртибен саклауны тәэмин итү | Башкарма комитетның мәгълүмати сәясәт һәм җәмәгатьчелек белән элемтә идарәсе | 2025-2027 еллар | Үткәрелгән гавами чаралар буенча әзерләнгән хисаплар саны, берәмлек | 45 | 46 | 47 | 48 | - | - | - | - | Шәһәрдә милләтара һәм конфессияара татулыкны саклау өчен уңай атмосфера тудыру |
| 2. | Милли җәмгыятьләр рәисләренең квартал | Мәдәният идарәсе | 2025-2027 | Үткәрелгән чаралар саны, | 4 | 4 | 4 | 4 | - | - | - | - | Шәһәр территориясендә |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | саен Федераль Миграция хезмәте идарәсе вәкилләре белән очрашуы | | еллар | берәмлек | | | | | | | | | яшәүче халыкларның милли-мәдәни үсеше |
| 3. | Милли җәмгыятьләр рәисләренең Татарстан халыклары Ассамблеясының Күчмә утырышларында катнашуы | Мәдәният идарәсе | 2025-2027 еллар | Катнашучылар саны, кеше | 4 | 4 | 4 | 4 | - | - | - | - | Шәһәрдә яшәүче халыкларның милли-мәдәни үсеше, милли һәм дини нигездә экстремизмны профилактикалау |
| Бурычның исеме: 2. Россиянең традицион рухи-әхлакый һәм мәдәни-тарихи кыйммәтләре нигезендә, шул исәптән балаларны һәм яшьләрне патриотик тәрбияләү, тарихи туган якны өйрәнүне үстерү һәм Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы дәүләт символларына ихтирамлы мөнәсәбәт формалаштыру юлы белән гражданнар бердәмлеген һәм гомумроссия гражданлык тәңгәллеген (гражданнар үзаңын) ныгыту | | | | | | | | | | | | | |
| 4. | Дини оешмаларга конфессияара үзара аңлашуга һәм татулыкка булышлык иткән мәдәни-агарту һәм хәйрия программаларын тормышка ашыруда ярдәм күрсәтү (Раштуа, Пасха, Чукындыру хөрмәтенә тәре йөреше, Ураза бәйрәме, Корбан бәйрәме, Хәтер көннәре) | Башкарма комитетның мәгълүмати сәясәт һәм җәмәгатьчелек белән элемтә идарәсе | 2025-2027 еллар | Катнашучылар саны, кеше | Фактта | Фактта | Фактта | Фактта | - | - | - | - | Шәһәрдә милләтара һәм конфессияара бердәмлеккә булышлык итү өчен уңай атмосфера булдыру |
| 5. | Казан епархиясе рус православие чиркәвенең Кама аръягы благочиниесы һәм ТР мөселман нарыкының Диния нәзарәте мөхтәсе | Башкарма комитетның мәгълүмати сәясәт һәм җәмәгатьчелек белән элемтә | 2025-2027 еллар | Үткәрелгән чаралар саны, берәмлек | 8 | 8 | 8 | 8 | - | - | - | - | Шәһәрдә милләтара һәм конфессияара бердәмлеккә булышлык итү өчен уңай |

| | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | бәтенең берлектә эшләве өчен шартлар тудыру: социаль, хәйрия чаралары, үзара визитлар, түгәрәк өстәлләр һ.б. | идарәсе | | | | | | | | | | атмосфера булдыру |
| 6. | «Ак мәчет» мәчетендә яшь Коръән укучыларның ел саен үткәрелә торган республикаара конкурсын уздыруда ярдәм күрсәтү | Башкарма комитетның мәгълүмати сәясәт һәм җәмәгатьчелек белән элемтә идарәсе | 2025-2027 еллар | Катнашучылар саны, кеше | 171 | 172 | 173 | 174 | - | - | - | - | Шәһәрдә милләтара һәм конфессияара бердәмлеккә булышлык итү өчен уңай атмосфера булдыру |
| Бурычның исеме: 3. Яр Чаллы шәһәренең этномәдәни һәм тел күптөрлелеген саклау һәм аңа ярдәм итү, татар һәм рус телләренең (милләтара аралашу теле буларак рус телен дә кертеп) яшәве өчен шартлар тудыру, барлык халыкларның туган телләрен һәм мәдәниятләрен үстерү, шулай ук рус теле, Россия Федерациясенең хокукый нигезләре, Татарстан халыкларының традицияләре һәм мәдәнияте белән танышу аша мигрантларның социомәдәни адаптациясенә һәм Россия җәмгыятенә интеграциясенә ярдәм итү | | | | | | | | | | | | |
| 7. | «Илһамлы каләм» республика конкурсының муниципаль турын оештыру | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе | 2025-2027 еллар | Катнашучылар саны, кеше | 1 030 | 1 035 | 1 040 | 1 045 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 25,0 | 25,0 | 25,0 | Балаларны һәм яшүсмерләрне мәдәни-тарихи социальләштерү |
| 8. | Идел буе халыкларының «Мәдәниятләр диалогы» фестивален оештыру һәм үткәрү | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе | 2025-2027 еллар | Катнашучылар саны, кеше | 65 | 70 | 75 | 80 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 30,0 | 30,0 | 30,0 | Балаларны һәм яшүсмерләрне мәдәни-тарихи социальләштерү |
| 9. | «Татар малае» муниипаль конкурсын оештыру һәм үткәрү (1-4 сыйныфлар) | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе | 2025-2027 еллар | Катнашучылар саны, кеше | 130 | 135 | 140 | 145 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге | 50,0 | 50,0 | 50,0 | Балаларны һәм яшүсмерләрне мәдәни-тарихи социальләштерү |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | бюджеты | | | | |
| 10. | «Татар малае» муниипаль конкурсын оештыру һәм уткәрү (5-8 сыйныфлар) | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе | 2025-2027 еллар | Катнашучы лар саны, кеше | 130 | 135 | 140 | 145 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 50,0 | 50,0 | 50,0 | Балаларны һәм яшүсмерләрне мәдәни-тарихи социальләштерү |
| 11. | «Татар малае», «Татар кызы» муниипаль конкурсын оештыру һәм уткәрү (мәктәпкәчә яшьтәгеләр) | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе | 2025-2027 еллар | Катнашучы лар саны, кеше | 230 | 235 | 240 | 245 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 70,0 | 70,0 | 70,0 | Балаларны һәм яшүсмерләрне мәдәни-тарихи социальләштерү |
| 12. | «Мин татарча сөйләшәм» республика конкурсының муниципаль турын оештыру | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе | 2025-2027 еллар | Катнашучы лар саны, кеше | 130 | 135 | 140 | 145 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 25,0 | 25,0 | 25,0 | Балаларны һәм яшүсмерләрне мәдәни-тарихи социальләштерү |
| 13. | «Татар кызы» муниипаль конкурсын оештыру һәм уткәрү (1-4 сыйныфлар) | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе | 2025-2027 еллар | Катнашучы лар саны, кеше | 73 | 75 | 80 | 83 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 50,0 | 50,0 | 50,0 | Мәктәп яшендәге балаларны мәдәни-тарихи социальләштерү |
| 14. | «Татар кызы» муниипаль конкурсын оештыру һәм уткәрү (5-8 сыйныфлар) | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе | 2025-2027 еллар | Катнашучы лар саны, кеше | 0 | 0 | 55 | 55 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 0 | 25,0 | 25,0 | Мәктәп яшендәге балаларны мәдәни-тарихи социальләштерү |
| 15. | Туган тел көнен уткәрү | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе | 2025-2027 еллар | Катнашучы лар саны, кеше | 70 | 73 | 77 | 80 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль | 30,0 | 30,0 | 30,0 | Балаларны һәм яшүсмерләрне мәдәни-тарихи |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | берәмлеге бюджеты | | | | социальләштерү |
| 16. | «Бердәмлек» шәһәр программасын оештыру һәм үткәрү | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе | 2025-2027 еллар | Катнашучылар саны, кеше | 1 030 | 1 035 | 1 040 | 1 045 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 25,0 | 25,0 | 25,0 | Балаларны һәм яшүсмерләрне мәдәни-тарихи социальләштерү |
| 17. | Мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренең балалар коллективлары арасында «XXI гасыр йолдызчыклары» мунииипаль конкурсын оештыру һәм үткәрү | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе | 2025-2027 еллар | Катнашучылар саны, кеше | 330 | 335 | 340 | 345 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 50,0 | 50,0 | 50,0 | Мәктәпкәчә яшьтәге балаларны мәдәни-тарихи социальләштерү |
| 18. | Гаилә, мәхәббәт һәм тугрылык сакчылары изге Петр һәм Феврония Муромскийлар истәлеге көненә чаралар оештыру һәм үткәрү | Мәдәният идарәсе | 2025-2027 еллар | Катнашучылар һәм тамашачылар саны, кеше | 330 | 335 | 340 | 345 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 30,0 | 30,0 | 30,0 | Халыкны мәдәни-тарихи социальләштерү |
| 19. | Милли җәмгыятьләр спартакиадасын оештыру һәм үткәрү | Мәдәният идарәсе | 2025-2027 еллар | Катнашучылар һәм тамашачылар саны, кеше | 230 | 235 | 240 | 245 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 15,0 | 15,0 | 15,0 | Бердәм мәдәни киңлек формалаштыру, шәһәрдә яшәүче халыклар вәкилләренең милли спорт төрләрен, традицион уеннарны популярлаштыру |
| 20. | «Ариран» корея җәмгыяте белән | Мәдәният идарәсе | 2025-2027 | Катнашучылар һәм | 180 | 190 | 200 | 210 | Яр Чаллы шәһәре | 5,0 | 5,0 | 5,0 | Корея халыкларының |

| | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | берлектә Көнчыгыш Яңа елын оештыру һәм үткәрү | | еллар | тамашачылар саны, кеше | | | | | муниципаль берәмлеге бюджеты | | | | мәдәни төрлелеген һәм традицияләрен саклау |
| 21. | Таҗик, лезгин, азербайҗан, үзбәк, казах, башкорт җәмгыятьләрендә «Нәүрүз» милли бәйрәмен оештыру һәм үткәрү | Мәдәният идарәсе | 2025-2027 еллар | Катнашучылар һәм тамашачылар саны, кеше | 235 | 240 | 245 | 250 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 10,0 | 10,0 | 10,0 | Халыкларны мәдәни-тарихи социальләштерү |
| 22. | Яр Чаллы шәһәрендә «Нәүрүз» милли бәйрәмен оештыру һәм үткәрү | Мәдәният идарәсе | 2025-2027 еллар | Катнашучылар һәм тамашачылар саны, кеше | 585 | 590 | 595 | 600 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 50,0 | 50,0 | 50,0 | Халыкларны мәдәни-тарихи социальләштерү |
| 23. | «Немец мәдәнияте көне» чарасын оештыру һәм үткәрү | Мәдәният идарәсе | 2025-2027 еллар | Катнашучылар һәм тамашачылар саны, кеше | 150 | 160 | 170 | 180 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 5,0 | 5,0 | 5,0 | Немец халкы мәдәнияте төрлелеген һәм традицияләрен саклау |
| 24. | «Уяв» чуаш милли-йола бәйрәмен оештыру һәм үткәрү | Мәдәният идарәсе | 2025-2027 еллар | Катнашучылар һәм тамашачылар саны, кеше | 225 | 230 | 235 | 240 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 30,0 | 30,0 | 30,0 | Халыкны мәдәни-тарихи социальләштерү |
| 25. | «Иван Купала» славян халык-йола бәйрәмен оештыру һәм үткәрү | Мәдәният идарәсе | 2025-2027 еллар | Катнашучылар һәм тамашачылар саны, кеше | 1 035 | 1 035 | 1 040 | 1 045 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 75,0 | 75,0 | 75,0 | Халыкны мәдәни-тарихи социальләштерү |
| 26. | «Питрау» шәһәр халык-йола бәйрәмен оештыру | Мәдәният идарәсе | 2025-2027 | Катнашучылар һәм | 665 | 670 | 675 | 680 | Яр Чаллы шәһәре | 75,0 | 75,0 | 75,0 | Халыкны мәдәни-тарихи |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | һәм үткәрү | | еллар | тамашачылар саны, кеше | | | | | муниципаль берәмлеге бюджеты | | | | социальләштерү |
| 27. | «Нардуган» традицион керәшен йола бәйрәмен оештыру һәм үткәрү | Мәдәният идарәсе | 2025-2027 еллар | Катнашучылар һәм тамашачылар саны, кеше | 300 | 300 | 300 | 300 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 50,0 | 50,0 | 50,0 | Халыкны мәдәни-тарихи социальләштерү |
| 28. | Мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә тәрбияләнүчеләр өчен «Салават күпере төсләре» күңел ачу-танып-белү программасы | Мәдәният идарәсе | 2025-2027 еллар | Концертлар саны, берәмлек | 16 | 17 | 18 | 19 | - | - | - | - | Балаларны мәдәни-тарихи социальләштерү |
| 29. | Милли җәмгыятьләр яшьләре өчен «Мәхәббәт хакына» конкурс-күңел ачу программасы | Мәдәният идарәсе | 2025-2027 еллар | Катнашучылар һәм тамашачылар саны, кеше | 283 | 283 | 283 | 283 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 15,0 | 15,0 | 15,0 | Яшьләрне мәдәни-тарихи социальләштерү |
| 30. | Кече яшьтәге мәктәп балалары өчен «Милли курчак» шәһәр конкурсы | Мәдәният идарәсе | 2025-2027 еллар | Конкурста катнашучылар саны, кеше | 14 | 14 | 14 | 14 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 25,0 | 25,0 | 25,0 | Балаларны мәдәни-тарихи социальләштерү |
| 31. | Милли җәмгыятьләрнең «Дус-туганлык – иң зур байлык» фестивале | Мәдәният идарәсе | 2025-2027 еллар | Катнашучылар һәм тамашачылар саны, кеше | 1 010 | 1 010 | 1 010 | 1 010 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 130,0 | 130,0 | 130,0 | Шәһәрдә һәм республикада яшәүче халыкларның мәдәни күптөрлелеген саклау һәм аңа карата позитив кыйммәтләр, |

| | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | | хөрмәт формалаштыру |
| 32. | Туган тел фестивале | Мәдәният идарәсе | 2025-2027 еллар | Катнашучылар һәм тамашачылар саны, кеше | 355 | 355 | 355 | 355 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 5,0 | 5,0 | 5,0 | Яр Чаллы шәһәрендә яшәүче халыклар телләренең телләр күптөрлелеген саклау һәм үстерү |
| 33. | Гомуми белем бирү оешмаларының укучылары өчен милли җәмгыятьләрнең бүлмәләре буенча экскурсияләр | Мәдәният идарәсе | 2025-2027 еллар | Экскурсияләр саны, берәмлек | 30 | 30 | 30 | 30 | - | - | - | - | Балаларны һәм яшүсмерләрне мәдәни-тарихи социальләштерү |
| 34. | Башкорт җәмгыяте белән берлектә «Карга боткасы» милли бәйрәмен оештыру һәм үткәрү | Мәдәният идарәсе | 2025-2027 еллар | Катнашучылар һәм тамашачылар саны, кеше | 1000 | 1050 | 1100 | 1150 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 5,0 | 5,0 | 5,0 | Яр Чаллы шәһәрендә яшәүче халыклар мәдәниятенең милли күптөрлелеген саклау һәм үстерү |
| 35. | «Терендез» әрмән милли бәйрәмен оештыру һәм үткәрү | Мәдәният идарәсе | 2025-2027 еллар | Катнашучылар һәм тамашачылар саны, кеше | 200 | 210 | 215 | 220 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 5,0 | 5,0 | 5,0 | Яр Чаллы шәһәрендә яшәүче халыклар мәдәниятенең милли күптөрлелеген саклау һәм үстерү |
| 36. | Фин-угыр халыкларының «Без бер агач тармаклары» халык иҗаты фестивален оештыру һәм үткәрү | Мәдәният идарәсе | 2025-2027 еллар | Катнашучылар һәм тамашачылар саны, кеше | 1000 | 1000 | 1000 | 1000 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 100,0 | 100,0 | 100,0 | Халыкны мәдәни-тарихи социальләштерү |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 37. | «Шорыкйол пайрем» мари милли бәйрәмен оештыру һәм үткәрү | Мәдәният идарәсе | 2025-2027 еллар | Катнашучылар һәм тамашачылар саны, кеше | 230 | 230 | 230 | 230 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 5,0 | 5,0 | 5,0 | Халыкны мәдәни-тарихи социальләштерү |
| 38. | «Каз өмәсе» халык-йола бәйрәме | Мәдәният идарәсе | 2025-2027 еллар | Катнашучылар һәм тамашачылар саны, кеше | 602 | 602 | 602 | 602 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 75,0 | 75,0 | 75,0 | Халыкны мәдәни-тарихи социальләштерү |
| 39. | «Май чабу» шәһәр бәйрәмен оештыру һәм үткәрү | Мәдәният идарәсе | 2025-2027 еллар | Катнашучылар һәм тамашачылар саны, кеше | 8 350 | 8 355 | 8 360 | 8 365 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 75,0 | 75,0 | 75,0 | Халыкны мәдәни-тарихи социальләштерү |
| 40. | «Милли бәйрәмнәр» милли бәйрәмнәр буенча фольклор кич утырулар» шәһәр проекты | Мәдәният идарәсе | 2025-2027 еллар | Катнашучылар һәм тамашачылар саны, кеше | 160 | 170 | 175 | 180 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 30,0 | 30,0 | 30,0 | Балаларны һәм яшьләрне мәдәни-тарихи социальләштерү |
| 41. | «Сабан туе» милли бәйрәмен оештыру һәм үткәрү | Мәдәният идарәсе | 2025-2027 еллар | Катнашучылар һәм тамашачылар саны, кеше | 17 500 | 18 000 | 18 500 | 19 000 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 332,8 | 332,8 | 332,8 | Яр Чаллы шәһәрендә яшәүче халыкларның милли күптөрлелеген саклау һәм үстерү |
| 42. | Татарстан Республикасы көненә һәм Яр Чаллы шәһәре көненә багышланган шәһәр бәйрәмен оештыру һәм үткәрү | Мәдәният идарәсе | 2025-2027 еллар | Катнашучылар һәм тамашачылар саны, кеше | 14 800 | 15 000 | 15 500 | 15 800 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 150,0 | 150,0 | 150,0 | Халыкны мәдәни-тарихи социальләштерү |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 43. | «Идел буе этносы һәм мәдәнияте» мәдәни-белем бирү проекты | Мәдәният идарәсе | 2025-2027 еллар | Катнашучылар һәм тамашачылар саны, кеше | 125 | 130 | 135 | 140 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 72,0 | 72,0 | 72,0 | Яр Чаллы шәһәрендә яшәүче халыкларның милли күптөрлелеген саклау һәм үстерү |
| 44. | «Тәм-том» кулинария зонасы» милли ризыклар фестивале | Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе | 2025-2027 еллар | Катнашучылар саны, кеше | 100 | 110 | 120 | 130 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 35,0 | 35,0 | 35,0 | Яшьләр арасында шәһәребез һәм Республика мәдәниятен һәм тарихын өйрәнүгә кызыксынуны үстерү |
| 45. | «Мин – патриот» интеллектуаль уен | Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе | 2025-2027 еллар | Катнашучылар саны, кеше | 115 | 120 | 125 | 130 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 12,0 | 12,0 | 12,0 | Яшьләр арасында шәһәребез һәм Республика мәдәниятен һәм тарихын өйрәнүгә кызыксынуны үстерү |
| 46. | «Татар квест» проекты | Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе | 2025-2027 еллар | Катнашучылар саны, кеше | 150 | 155 | 160 | 165 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 15,0 | 15,0 | 15,0 | Яшьләр арасында шәһәребез һәм Республика мәдәниятен һәм тарихын өйрәнүгә кызыксынуны үстерү |

| | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 47. | «Халкым чишмәсе» региональ яшьләр татар милли иҗат фестивален оештыру һәм үткәрү | Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе | 2025-2027 еллар | Катнашучылар саны, кеше | 195 | 200 | 205 | 210 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 50,0 | 50,0 | 50,0 | Яшьләр арасында шәһәребез һәм Республика мәдәниятен һәм тарихын өйрәнүгә кызыксынуны үстерү |
| 48. | «Татар егете» региональ проектын оештыру һәм үткәрү | Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе | 2025-2027 еллар | Катнашучылар саны, кеше | 105 | 110 | 115 | 120 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 50,0 | 50,0 | 50,0 | Яшьләр арасында шәһәребез һәм Республика мәдәниятен һәм тарихын өйрәнүгә кызыксынуны үстерү |
| 49. | «Серле сандык» («Волшебный сундук») шәһәр милли иҗат проектын оештыру һәм үткәрү | Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе | 2025-2027 еллар | Катнашучылар саны, кеше | 110 | 115 | 120 | 125 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 30,0 | 30,0 | 30,0 | Яшьләр арасында шәһәребез һәм Республика мәдәниятен һәм тарихын өйрәнүгә кызыксынуны үстерү |
| 50. | Татар яшьләре форумы | Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе | 2025-2027 еллар | Катнашучылар саны, кеше | 85 | 90 | 95 | 100 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 50,0 | 50,0 | 50,0 | Яшьләр арасында шәһәребез һәм Республика мәдәниятен һәм тарихын өйрәнүгә кызыксынуны үстерү |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Бурычның исеме: 4. Дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыруны мәгълүмати тәэмин итү, толерантлык, гражданнар бердәмлеге идеяләрен пропагандалау, башка мәдәниятләргә хөрмәт күрсәтү өчен бердәм мәгълүмати киңлек формалаштыру | | | | | | | | | | | | | |
| 51. | «Интернет» челтәрендә Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында һәм шәһәрнең массакүләм мәгълүмат чараларында чараларны анонслау, пост-релизлар бастырып чыгару | Мәдәният идарәсе | 2025-2027 еллар | Бастырып чыгарылган мәкаләләр, анонслар, телетапшы рулар, интервью һәм чыгышлар саны | 18 | 19 | 20 | 21 | - | - | - | - | Толерантлык идеяләрен пропагандалау һәм тарату, милләтара һәм конфессияара бердәмлекне саклау өчен бердәм мәгълүмати киңлек формалаштыру |
| 52. | Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында, «Интернет» челтәрендә этникара һәм динара мөнәсәбәтләр не нызгытуга, дини һәм этник түзеп тора алмаучанлык һәм дискриминациягә каршы торуга булышлык итә торган мәгълүматлар урнаштыру, шулай ук шәһәрдә үткәрелә торган этникара һәм динара мөнәсәбәтләр не нызгытуга булышлык итә торган чараларны яктыртып бару | Мәдәният идарәсе | 2025-2027 еллар | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында чыккан мәкаләләр саны, берәмлек | 11 | 12 | 13 | 14 | - | - | - | - | Шәһәрдә милләтара һәм конфессияара бердәмлеккә булышлык итү өчен уңай атмосфера булдыру |

| | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 53. | Дини оешмалар һәм культ корылмалары турында мәгълүматлар банкын квартал саен формалаштыру һәм актуальләш терү | Башкарма комитетның мәгълүмати сәясәт һәм җәмәгатьчелек белән элемтә идарәсе | 2025-2027 еллар | Мәгълүмат лар базасын яңартулар саны, берәмлек | 4 | 4 | 4 | 4 | - | - | - | - | Шәһәрдә милләтара һәм конфессияара бердәмлеккә булышлык итү өчен уңай атмосфера булдыру |
| 54. | Туган телдә (татар, рус) иң яхшы дәрес, чаралар буенча җыентык бастырып чыгару | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе | 2025-2027 еллар | Данәләр саны | 100 | 100 | 100 | 100 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 50,0 | 25,0 | 25,0 | Балаларны һәм яшүсмерләрне мәдәни-тарихи социальләштерү |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы

Н.И. Галиева